# Яшьлек

*Гыйнвар - Февраль 2017 ел*



## Таныйсызмы?



## Атна шәхесе - Эльвира апа!



## Language World

# Language World



Languge World - әлеге лингвистик лагерьда кешенең акылы һәм күңел дөньясы, җаны бердәм процесста үсә, формалаша. Бу үсеш югары дәрәҗәдәге профессионаллар күзәтүе астында алып барыла. Әгәр дә инглиз телен яхшырак беләсең килсә, сиңа—шунда. Лагерьда барлык инглиз теле дәресләре бик кызыклы үтә: караоке, мастер класслар, видеодәресләр, викториналар, лекцияләр, рольле уеннар, дебатлар - болар бөтенесе дә чит илдән ( Һиндстан, Португалия, Австралия, Бразилия, Испания) килгән әйдаманнар белән берлектә



үткәрелә. Безнең гимназиянең 8 нче сыйныф укучылары Авзалтдинова Гүзәл, Шәрифуллина Рузилә һәм мин, Хәбирова Наилә, әлеге лагерьда булып кайттык. Безгә Languge World лагере инглиз телендә фикер йөртергә, тәҗрибә тупларга ярдәм итте.



Авзалтдинова Гүзәл: "Минем өчен иң кызыклысы чит ил кешеләре белән очрашу, алар белән төрле уеннарда катнашу булды. Шулай ук без аларның тормышлары, яшәгән илләре турында тулырак мәгълүмат алдык."

Шәрифуллина Рузилә: " Ә минем өчен иң кызыклысы дебатлар булды. Мин инглиз теледә аралашырга, үз фикеремне дәлилләргә өйрәндем. Хәтта уйларым да инглизчә иде."

Минем уйлавымча, видеодәресләр - иң истә калган мизгелләр. Видеодәресләр - ул инглиз телендә төрле темаларга карата дәресләр карау, тыңлау. Инглиз телендә чит ил кешеләре белән янәшә утырып караоке җырлау да онытылмаслык булып истә калды!Инглиз теледә өйрәнүдән тыш, дискотекалар ,төрле кичәләр, конкурслар булды. Лагерьга елның төрле сезонында барырга





мөмкин.

# Атна шәхесе - Эльвира апа!



Бу атнаның шәхесе - иң чибәр Эльвира апабыз! Эльвира апа - , иң беренче чиратта, балаларның таянычы һәм дусты. Ул һәрвакытта да балаларның күңелен күрә һәм ярдәмгә килергә әзер булып тора. Шул ук вакытта ул - гимназиядә “Рәсәй балалары хәрәкәте” нең оештыручысы да.

**Туган көне: 20.10.89**
**Ф.И.О.: Яковлева Эльвира Илдар кызы**
**Яраткан фильмы: “Титаник”**
**Яраткан ризыгы: бәлеш**



**-Исәнмесез , Эльвира апа!**
-Хәерле көн, Айзилә.
**-Тормышыгызда сезнең өчен ни мөһим нәрсә?**
- Әти-әнием, гаиләм.
**-Сезнең тормышыгызда берәр нинди “безбашенный” поступок бар идеме?**
- Бар, ләкин мин аны сиңа сөйләмим (көлә).
**-Сез үзегезне уңышлы кеше дип санийсызмы?**
- Әйе.
**-Нинди 3 әйбердән куркасыз?**
- Бүредән һәм ураганнан.




**- “Эх туган көн, туган көн...” дигән җырны дәвам итегез.**
- Бәйрәм итә торган көн.
**- Әгәр дә вакыт машинасына утырып, үткәнгә кайтып булса, сез нәрсә үзгәртер идегез?**
- Үзгәртмәс идем, ягъни кайтып та тормас идем.
**- Кечкенә чагыгызда нинди профессия сайлыйсыгыз килгән иде?**
- Табиб буласым килгән иде, ләкин әнием рөхсәт итмәде.
**- Сез Рәсәй балалары хәрәкәтенең бер өлеше булуыгызга шатмы?**
- Әлбәттә, шат!



Җәмилова Айзилә

# Ил агасы



20 гыйнвар көнне,Татарстан Республикасының бөек шәхесе Минтимер Шәймиев 80 яшьлек юбилеен билгеләп үтте.Әлеге зур бәйрәм уңаеннан, безнең мәктәптә дә аңа багышланган линейка, сыйныф сәгатьләре һәм кызыклы күргәзмәләр оештырылды.Ә 6-нчы сыйныф укучылары Минтимер Шәймиевка бүләккә зур топиарий ясау акциясен оештырдылар.Әлеге акциядә барлык укучылар да актив катнаштылар. Афәрин!

**Минтимер Шәймиев турында кызыклы фактлар**

1. Минтимер Шәймиев күпбалалы гаиләдә тугызынчы бала булып туа. «Мондый гаиләдә сабырлыкка, олыларны тыңларга, бердәмлеккә өйрәнәсең. Монда мин-минлек, үз-үзеңне генә ярату сыйфатлары юк».
2. Кушаматы – Чапкын. Бу – нәселдән бирелгән кушамат. Минтимер аганың бабасын кулак дип тапканнар, әмма сөргенгә сөрмәгәннәр. Ул Сабантуй өчен чабышкы атлар асраган. Аларны бу көн өчен ел буе әзерләгән һәм Минзәлә өязендә беренчелекне бераүгә дә бирмәгән. «Чапкын» кушаматы шулай ябышып калган.
3. Балачак хыялы – гармунда уйнарга өйрәнү. «Авылда гармун тартучы егетләр бар иде. Абый белән минем гармунда уйнавымны ишетү – әтинең зур хыялы иде. Әмма миннән берни дә килеп чыкмады. Гармунчыларга карата яшерен көнләшү бар иде. 60 ка якынлашканда, бу теләк кабат калкып чыкты. Буш вакытларымда кулыма гармун ала башладым. Уйнап җибәрдем бит. Бу - могҗиза! «Алмагачлары», «Озата барма», «Күбәләгем», «Җидегән чишмә»не гармунда суза алам».
4. Азарт белән укый. «Тынгысыз малай булдым. Безнең авыл аша узып, районга математика укытучысы эшкә йөри иде. Әгәр мин берәр гамәлне чишә алмасам, ничек чишәргә кирәклеген сорарга дип, аны саклап торам».
5. Китап укырга ярата. Бигрәк тә Тукайны. «Мин гомерем буе Тукай шигърияте белән мавыктым. Такташ иҗаты да ошый. Ул – безнең Маяковский. Район китапханәсендәге бөтен китапны укып чыктым. Татар язучыларыннан Әмирхан Еники, Кави Нәҗми, чит ил әдәбиятыннан Виктор Гюго тирән тәэсир ясады. Хәзер кабат Достоевскийны укыйсым килә. Аның иҗат киңлеген аңлау соңрак килде».





Низамова Сөмбел

# Таныйсызмы?

Хәерле көн, гимназяшки! Без, «Яшьлек» газетасаның редакторлары, сезгә бәйге игълан итәбез. Менә бу фотоларда безнең яраткан укытучыларыбызның яшь чаклары, сезгә кемнең-кем икәнен белергә һәм безгә хәбәр итәргә кирәк. Бүләк бик шәп, тизрәк бул!!!





















*Шәрифуллина Рүзилә*

# Туган телем - назлы гөлем



Белгәнебезчә, 21 нче февраль - Халыкара Туган тел көне! Бүгенге көндә дөнья халыклары алты мең телдә сөйләшә. Шуның яртысы диярлек юкка чыгу куркынычы астында. Татар теле – ЮНЕСКО тарафыннан бөтендөнья халыкара аралашу теле дип саналган 14 телнең берсе. Бу – туган телебез белән горурланырлык би-и-к мөһим факторларның берсе! Һәркем өчен дөньядагы барлык телләр арасында иң кадерлесе – тәүге кабат сөйләшә башлаган ана теле. Бу – безнең балачагыбыз, гаиләбез, җәмгыятьтәге беренче тапкыр аралашуыбыз теле. Халыкара туган тел көнендә барлык телләр дә тигез дип таныла, чөнки аларның һәркайсы кеше язмышы өчен җавап бирә, һәркайсы табигый мирас булып тора һәм без аны, һичшиксез, сакларга бурычлыбыз.

17-27 февраль көннәрендә гимназиядә дә Туган тел декадасы булып узды. Балалар туган телдә үткәрелгән төрле бәйгеләрдә катнаштылар, үзләре дә сыйныфлары белән бәйрәмнәр уздырдылар. Бу бәйрәмне 1 нче март көнне Мәдәният йортында узган “Туган тел көне” йомгаклады. Бу чарада төрле милләт вәкилләре бик рәхәтләнеп катнаштылар. Милли мәгариф буенча ресурслар үзәге буларак, бәйрәмне гимназия коллективы әзерләде һәм алып барды. Сценарийны "Ак калфак" оешмасы рәисе Усманова Энҗе Фәвис кызы әзерләде, бик зур рәхмәтләребезне җиткерәбез сезгә, Энҗе апа!

Җәмилова Айзилә

# Без-мультипликаторлар!




ТатарМультфильм - татар мулфильмнары чыгара торган Россия анимация студиясе. Ул 2009 елдан башлап балаларны кызыклы мультфильмнары белән сөендерә. ТатарМультфильмнын беренче мультфильме «Бала белән Күбәләк», анын геройлары Габдулла Тукайнын барыбызга да билгеле әсәреннән алынган.

Бу елны алар гимназиягә килеп киттеләр. Алар укучыларны үз ижаты белән таныштырдылар, мультфильмны компьютерда да һәм дәфтәр битендә ясарга өйрәттеләр. Шулай ук 5-8 укучылары ТАССРнын 100 еллык юбилеена багышланган конкурста да катнаштылар. Районнан берничә баланын гына рәсеме үтәчәк бу бәйгедә һәм ТатарМультфильм студиясенең беренче балалар белән ясалган мультфильмына керәчәк.



Сез дә 13 майга кадәр бу конкурста катнашып, электрон почтадан рәсемнәр жибәреп жиңә аласыз.



Шәрифуллина Рүзилә

Туган көн- гомер бәйрәме...

# Туган көн- гомер бәйрәме...





Ольга Сергеевна (08.01)
Ильмира Васильевна (30.01)
Алсу Миннезагировна (18.02)
2 нче сыйныф:
Васильев Раил (14.01)
Гыйләҗетдинов Рамил (11.01)
Коршунова Алинә (13.02)
3 нче сыйныф:
Хәбирова Алия (04.02)
Хаҗиева Лилиана (13.01)
4 нче сыйныф:
Васильев Радомир (25.02)
Козелков Андрей (19.01)
5 нче сыйныф:
Әхмәтов Рунар (05.01)
Гарипова Рүзилә (23.02)
Зиннәтуллин Айдар (16.02)
Чернышова Азалия (23.02)
Абдулкәримов Кәрим (01.01)
6 нчы сыйныф:
Мөхәммәдиева Алия (10.02)
Мөхәммәтшина Алия (19.01)
7 нче сыйныф:
Хәйруллин Данил (04.01)
Сәләхова Сөмбел (25.02)
Никитин Динар (22.01)
8 нче сыйныф:
Низамова Сөмбел (27.02)
Нуруллин Айгиз (12.01)
Смирнов Роман (21.02)
9 нчы сыйныф:
Исламова Эльза (03.01)
Хөсәенова Энҗе (25.02)
10 нчы сыйныф:
Гайниева Регина (13.01)
Дәүләтова Чулпан (08.01)
11 нче сыйныф:
Низамова Алинә (19.01)
Шәфыйкова Чулпан (02.02)
Миншина Зилә (16.02)
Гомәрова Диләрә (03.02)
Никитина Алена (05.02)
Газизов Тимур (22.01)



**Баш мөхәррир** —Низамова Сөмбел
**Әдәби консультант-** Җәмилова Айзиля
**Бүлек мөхәррирләре** - Хәбирова Наилә
**Проект җитәкчеләре** — татар теле һәм әдәбияты укытучылары Ильина Миләүшә Әхтәм кызы, Заһриева Гөлнара Рөстәм кызы.

423700, ТР, Минзәлә шәһәре,
Чаллы тракты, 1А,
тел./факс (885555)3-51-71,
www.gimnazia-menz.edusite.ru
e-mail: sch1104_tg@mail.ru
Instagram: @gimnaziya__official
http://vk.com/id324010745